ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.04.2020 Олы Кайбыч ав. № 182

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү срогын озынайту турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль ярдәмнең аерым чараларын күрсәтү срогын озайту турында» 2020 елның 01 апрелендәге 241номерлы карары нигезендә һәм короновирус инфекциясе таралу куркынычын минимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 12 сентябрендәге 524 номерлы карары белән билгеләнгән җан башына уртача керем 20,0 мең сумга кадәр булган гаиләләргә муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында балаларны карап торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация бирүне, аларны түләү чоры 2020 елның 1 сентябренә кадәр дәвам иткәндә, аларны алу өчен кабат гариза бирмичә, 2020 елның 1 октябренә кадәр озайтырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ә. Биккуловага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров